Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге составына керүче
Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

« 14 » ноябрь 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2024 елның 14 ноябре 14.00 сәг.Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылы гражданнар җыенында “2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы? дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде.

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Татар Әхтиялы авылындагы чишмәне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Әхтиялы торак пунктының Ключевая урамындагы юл өслегенә вак таш сатып алу).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 91 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 55 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 50 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 5 граждан

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыенын узган  дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. “2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай  авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә ризамы?   дигән сорау буенча карар кабул ителде. Акчаны түбәндәге эшләргә юнәлтергә:

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (Татар Әхтиялы авылындагы чишмәне төзекләндерү өчен материаллар сатып алу);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Әхтиялы торак пунктының Ключевая урамындагы юл өслегенә вак таш сатып алу;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына керту өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова